РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОУСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЯҢА УСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Юрид.адрес: 423980, РТ, Муслюмовский район, с. Новые Усы, ул. Советская, 30
Факт.адрес: 423980, РТ, Муслюмовский район, с. Новые Усы, ул. Советская, 30
Тел./факс: 8-85556-32030/25866 (бух.) - Элект. адрес: Nusin.Mus@tatar.ru
ИНН 1629004001, КПП 162901001, ОГРН 1061687005302, ОКТМО 92642455

**Яңа Усы авылы** **«27» январь 2022 ел**

**КАРАР №5**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Яңа Усы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары, «2022 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе күләмен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Мөслим муниципаль районының Яңа Усы авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2022 елның 1 февраленнән Мөслим муниципаль районының Яңа Усы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен, 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә, 6964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru сайты буенча урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольда тотуны үз өстемә алам.

**Яңа Усы авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Романова Г.С.**

Мөслим муниципаль районы
Яңа Усы авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2022 елның 27 нче январь
5 нче номерлы карарына
1 нче кушымта

**2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Яңа Усы авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе** ***(сум)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү. | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яраклар бирү һәм китерү. | 3550,51 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка илтү. | 1368,39 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү). | 2045,78 |
| **Барлыгы** | **6964,68** |

Мөслим муниципаль районы
Яңа Усы авыл җирлеге
Башкарма комитеты
2022 елның 27 нче январь
5 нче номерлы карарына
2 нче кушымта

**2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Яңа Усы авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сум)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү. | 0,00 |
| 2. Кәфенләү. | 1079,31 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәк-яраклар бирү һәм китерү. | 2501,6 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка илтү. | 1393 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү). | 1990,77 |
| **Барлыгы** | **6964,68** |